**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Сарман авыл җирлегендә 2024 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

31 март 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы «Сарман авыл җирлеге Сарман торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Сарман торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Сарман торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Сарман авылында гражданнар җыены **карар итте:**

**1.** «Сарман авыл җирлеге Сарман торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Сарман торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына түбәндәге редакциядәге чаралар бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

1) Электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру), трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау
2) Янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү, ремонтлау;
3) Сарман торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сарман торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау
4) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Сарман торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү, балалар уен мәйданчыклары һәм МАФ урнаштыру);
5) Ремонтлау, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү.

2. Җыен нәтиҗәләрен Сарман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башлыгы ___________ Ф.М.Хәснуллин